**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

# 1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгы белән бәйле рәвештә Россия Федерациясе гражданнарының кайбер категорияләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында

1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгы белән бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. 2025 елның апрель – май айларында Татарстан Республикасы территориясендә даими яши торган Россия Федерациясе гражданнарының түбәндәге категорияләренә бер тапкыр акчалата түләү бирергә:

«Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясы 1 пунктындагы 1–3 пунктчаларында күрсәтелгән затлардан булган Бөек Ватан сугышы инвалидларына, Бөек Ватан сугышы ветераннарына, Икенче бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союздашлары тарафыннан корылган концлагерьлар, гетто һәм башка төрле ирексезләп ябып тоту урыннарында булган элеккеге балигълык яшенә җитмәгән тоткыннарга – 50 000 сум күләмендә;

Финляндия белән сугыш, Бөек Ватан сугышы, Япония белән сугыш чорында һәлак булган хәрби хезмәткәрләрнең тол хатыннарына (тол ирләренә), вафат булган Бөек Ватан сугышы инвалидларының һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарына (тол ирләренә), «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясы 1 пунктындагы 4 пунктчасында күрсәтелгән затлардан булган Бөек Ватан сугышы ветераннарына – 10 000 сум күләмендә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны үтәү белән бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны, шул исәптән бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне китертүгә тотыла торган чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне алар социаль ярдәм чаралары ала торган урыннарда бирүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 28 февраль
№ 168